РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ СТАРОИКШУРМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422066, Республика Татарстан, Сабинский район, с.Старая Икшурма, ул. Ленина, д.17
тел. 8(84362) 41-6-47

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ИКШЕРМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422066, Татарстан Республикасы, Саба районы, Иске Икшермә авылы, Ленин урамы, 17 йорт
тел.8(84362) 41-6-47

e-mail: sik.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
23.09.2018 г.

КАРАР
№ 26

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл жирлегендә гражданнардан үзара салым акчасы жыю һәм аны куллану буенча жирле референдум билгеләү турында

"Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре турында" 12.06.2002 №67-ФЗ Федераль законның 15 нче статьясына, "Россия Федерациясендә жирле үзидарәне оештыруның төп принциплары турында" 06.10.2003 №131-ФЗ Федераль законның 22.56 статьялары, Татарстан Республикасының "Жирле референдум турында" 24.03.2004 №23-ЗРТ 18 статьясы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл жирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясына туры китереп, Иске Икшермә авыл жирлеге Советының 20.09.2019 № 25 "Референдум уздыру инициативасы турында" карары, Иске Икшермә авыл жирлеге башкарма комитетының 20.09.2019 № 54 "Референдум уздыру инициативасы турында" карары нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл жирлеге КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл жирлегендә гражданнардан үзара салым акчасы жыю соравын кертү буенча жирле референдумны 2019 елның 17 ноябренә билгеләргә.

2. Жирле референдумга куеласы сорауларны түбәндәгечә расларга:

"Сез яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Иске Икшермә авыл жирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 2019 елда 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм аны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән ризамы:

- Иске Икшермә авылында автомобиль юлларын ремонтлау;
- Татар Икшермәсе авылында жирләү урыннарын төзекләндерү;
- Өч Нарат авылында автомобиль юлларын ремонтлау;

ӘЙЕ ЮК"

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион "Интернет" челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм жирлекнең мәгълүмат стендларында бастырырга.

4. Карар басылып чыккан (халыкка хәбәр ителгән) көннән соң үз көченә керә.

Иске Икшермә авыл жирлеге башлыгы: Н.Н.Нурмухаметов